ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.02.2021 № 157

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2014-2024 елларга Алабуга шәһәренең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү муниципаль программасын раслау турында» 2015 елның 10 ноябрендәге 1323 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларына карата таләпләрне раслау турында» 2013 елның 14 июнендәге карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2014-2024 елларга Алабуга шәһәренең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү муниципаль программасын раслау турында» 2015 елның 10 ноябрендәге 1323 номерлы карарына үзгәрешләр кертеп, Программа паспортын яңа редакциядә кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
"157" 12.02.2021 ел

карарына 1 нче кушымта

# ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2014-2024 елларга Алабуга шәһәренең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез булып торган норматив-хокукый актлар | Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2011 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>« «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару турында» Россия Федерациясенең 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2013 елның 14 июнендәге 503 номерлы карары;<br>Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының 2011 елның 6 маендагы 204 номерлы боерыгы белән расланган муниципаль берәмлекләрнең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын әзерләү буенча методик тәкъдимнәре; |

| | |
|---|---|
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ресурслардан нәтиҗәле файдалану концепциясен раслау турында» 2003 елның 11 апрелендәге 199 номерлы карары. |
| Программаның заказчысы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчеләре | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, «Алабуга муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш Департаменты» МУП |
| Программаны башкаручы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, «Алабуга муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш Департаменты» МУП, программа чараларын башкаруга муниципаль контрактлар төзегән, законнарда билгеләнгән тәртиптә оешмалары булган инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы хуҗалык субъектлары |
| Программаның максатлары | • кулланучыларны коммуналь хезмәтләр белән сыйфатлы һәм ышанычлы тәэмин итү;<br>• коммуналь инфраструктура системаларының нәтиҗәлелеген, тотрыклылыгын һәм ышанычлылыгын арттыру;<br>• торак-коммуналь комплексының энергия сыйдырышлылыгын киметү;<br>• Алабуга шәһәре торак-коммуналь комплексының тотрыклы, ышанычлы эшләвен һәм үсешен тәэмин итү;<br>• Алабуга шәһәренең озак вакытка исәпләнгән тотрыклы социаль-икътисадый үсешенә ярдәм итү, тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү<br>Алабуга шәһәренең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасы, Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре территориясендә эшчәнлек алып баручы коммуналь комплекс оешмаларының инвестиция һәм |

| | |
|---|---|
| | җитештерү программаларын эшләү өчен нигез документ булып тора. |
| Программаның бурычлары | • гамәлдәге төзелеш урыннарында коммуналь инфраструктураны арттыру һәм модернизацияләү мөмкинлеген тәэмин итү, аларның торышын яхшыртуның һәм торак төзелеше күләмнәрен арттыруның максатчан параметрларын тәэмин итү;<br>• коммуналь инфраструктураны үстерү һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру буенча икътисадый һ‛ем оештыру механизмнарын формалаштыру һ‛ем камилл‛ештерү;<br>• энергия ресурсларын сак тотуны сыйфатлы яхшыртуны тәэмин итә торган нәтиҗәле ресурслар саклаучы техника, технологияләр һәм материаллар куллану;<br>• ресурслар саклый торган технологияләр һәм яңа материаллар кулланып, капиталь ремонт оештыруның яңа механизмнарын кертү;<br>• тузган торак фондыннан гражданнарны күчерү өчен яңа төзелешкә җир кишәрлекләрен бүлеп бирүне гамәлгә ашыру;<br>• коммуналь инфраструктураның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру. |
| Иң мөһим максатчан күрсәткечләр | Җылылык белән тәэмин итү системасы:<br>• җылылык белән тәэмин итү системасының авария хәлендә булуы, норма буенча - 0,2 бер./км;<br>• кулланучылар тарафыннан транспортировкалау вакытында җылылык энергиясен югалту дәрәҗәсе 14% арттырмау;<br>• тулысынча алыштыруга мохтаҗ булган челтәрләрнең чагыштырма авырлыгын 5% арттырмау.<br><br>Су белән тәэмин итү системасы:<br>• су белән тәэмин итү системасының авария хәлендә булуы, норма буенча -0,5 бер./км;<br>• су белән тәэмин итү системасының тузуы 45% арттырмау; |

| | |
|---|---|
| | • эчәргә яраклы су сыйфатының билгеләнгән таләпләргә 90% туры килүе.<br><br>Ташландык суларны чыгару системасы:<br>• су чыгару системасында авария хәлендә булуы норма буенча -5,0 бер./км;<br>• агып төшүче суларның сыйфатына билгеләнгән таләпләргә 90 % туры китерү.<br><br>Газ белән тәэмин итү системасы:<br>• кулланучыларны газ белән тәэмин итү. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | Гамәлгә ашыру вакыты - 2020-2024 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны 2014 елдан алып 2024 елга кадәр финанслауның гомуми күләме 9 633,24 млн. сум тәшкил итә.<br>Программа чараларын финанслау чыганаклары:<br>Федераль бюджет, барлык дәрәҗәдәге бюджетлар, башка фондлар, шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә җайга салынулы оешмалар акчалары. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә түбәндәге күрсәткечләргә ирешеләчәк:<br>• ТКХ хезмәтләренә тарифлар үсешен тоткарлау;<br>• торак-коммуналь комплексының энергия сыйдырышлылыгын киметү;<br>• халыкка күрсәтелә торган коммуналь инфраструктура системаларының һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын арттыру. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | 1. Программа белән оператив рәвештә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, «Алабуга муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш Департаменты» МУП (килешү буенча) идарә итә.<br>2. Программаны гамәлгә ашыру механизмы түбәндәгеләрне күз алдында тота: |

| | |
|---|---|
| | 1) барлык мөмкин булган чыганаклардан финанслауның күпкырлылыгы;<br>2) һәр финанс елына Программа чараларын гамәлгә ашыру планнарын төзү;<br>3) Программаның эшчәнлек нәтиҗәлелеген квартал саен бәяләү индикаторлары буенча сыйфатын мониторинглау;<br>4) Программаның үтәлеше турында еллык хисап. |